**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“22” ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Бахтияр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу.

2) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: Бахтияр авылы сулыгы ярында су алу мәйданчыгы урнаштыру өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Мәңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Тахавиев Ф.К.